**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

**2024 елның 10 октябрендәге 4293 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Вахитов районында**
**ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитутның характеристикасы:

- йогынты ясала торган мәйдан – 3343 кв.м;
- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры: 16:50:000000:34398;
- урнашу урыны турында мәгълүмат: Казан шәһәре, Вахитов районы;
- билгеләү максаты: җәяү һәм транспортта узуны тәэмин итү;
- билгеләү вакыты: 3 ел;

1.2. гариза бирүче: «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитеты" муниципаль казна учреждениесе» (ОГРН 1071690066744, ИНН 1655147246, урнашу урыны адресы: 420015, Казан шәһәре, Театр урамы, 13 йорт);

1.3. билгеләү нигезләре: гариза бирүче гаризасы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы.

2. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә.

3. Әлеге карарның 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

5. Җир кишәрлегеннән алга таба файдаланганда гариза бирүчегә тәкъдим итәргә:

5.1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2017 елның 13 мартындагы 218од номерлы «Казан шәһәренең төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлеге территориясе чикләрендә территория чикләрен, саклау предметын һәм шәһәр төзелеше регламентларына таләпләрне раслау турында»гы әмере нигезендә чикләүләрне үтәргә;

5.2. 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында»гы федераль закон һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2010 елның 1 апрелендәге 183 номерлы «Истәлекле урын территориясеннән файдалану характеры, әлеге территориядән файдалануга чикләүләр һәм Казан шәһәренең истәлекле урыннары территориясендә хуҗалык эшчәнлегенә, проектлауга һәм төзүгә таләпләр турында нигезләмәне раслау хакында»гы әмере нигезендә чикләүләрне үтәргә;


5.3. Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының 2023 елның 11 маендагы 1311 номерлы «Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән федераль әһәмияткә ия «Казан Кремле ансамбле», XV гасыр – XX гасырның беренче чиреге (Татарстан Республикасы (Татарстан) мәдәни мирас объектын саклау зоналары чикләрен, җирләрдән файдалануның махсус режимнарын һәм әлеге зоналар территорияләре чикләрендә шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләрне раслау турында»гы әмере нигезендә чикләүләрне үтәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

1 номерлы кушымта
Казан шәһәре Башкарма
комитетының
2024 елның 10 октябрендәге
4293 номерлы карары белән
расланды

**Казан шәһәренең Вахитов районында**
**ачык сервитут йогынтысы өлкәсе чикләре**




Масштаб 1:1000

Координаталар системасы: МСК-16

| Шартлы билгеләр: | |
|---|---|
| 1 | яңа ясалган характерлы нокта |
| | билгеләнә торган сервитут чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлекләре чиге |
| | территорияләрдән файдалануның махсус шартлары |
| | кызыл линияләр (гамәлдәге) |
| | капиталь төзелеш объектлары |
| 16:50:010701 | кадастр кварталы |
| 16:50:000000:34398 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр |